ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«5) «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.».

## 2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 пунктының 5 пунктчасы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2021 елгы салым чоры өчен транспорт салымы исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 21 октябрь
№ 73-ТРЗ